Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

17 сентябрь 2026 ел №56

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2024 елның 27 июнендәге 253 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 135 статьясы, «Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 07 июнендәге 144-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2024 елның 27 июнендәге 253 номерлы карарына (Советның 2025 елның 30 апрелендәге 306 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Карарга түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә: «12. Хезмәт законнары нигезендә локаль норматив актлар белән премияләү системаларын билгеләгәндә, премияләрнең төрләре һәм аларның күләмнәре, хезмәткәрләргә премияләр түләү сроклары, нигезләре һәм шартлары, шул исәптән эшнең сыйфатын, нәтиҗәлелеген һәм дәвамлылыгын, хезмәткәрнең дисциплинар түләтүе булу-булмавын һәм башка күрсәткечләрне исәпкә алып билгеләнә.

Хезмәткәргә премия күләмен киметү турындагы шарт белән, аңа карата дисциплинар җинаять кылган өчен дисциплинар түләтү кулланылуга бәйле рәвештә, хезмәткәргә карата тиешле дисциплинар түләтү кулланылган чор өчен исәпләнә торган хезмәткәрнең хезмәт хакы составына керүче премияләргә карата гына гамәлгә ашырыла, ә премияне мондый киметү күләме хезмәткәрнең хезмәт хакы 20 проценттан артыграк айлык премия күләмен киметүгә китерә алмый.».

1.2. Карарның 12-14 пунктларын 13-15 пунктлар дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы

Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башлыгы урынбасарына, Совет рәисе урынбасарына йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т.Айбатов